СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**01 ноябрь 2024 ел** **№ 11**

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Курса авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылында Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 20 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 20 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылында Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 20 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 20 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Мәктәп урамнында яшәүчеләр

2нче этап: А.Алиш, Яр буе, К. Тинчурин урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә, түләү

күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренең юл япмасын чокырлы ремонтлау);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Урта Курса авылы обелиск бюстын сатып алу һәм алыштыру);

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне тәртипкә китерү (К. Тинчурин һәм Мәктәп урамнарындагы коеларны ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 16а йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Вафина